Татарстан Республикасы
Әлмәт муниципаль районы Рус Акташы авыл Советы

КАРАРЫ

12 декабрь 2024ел №97

Әлмәт муниципаль районы Рус Акташы авыл Советының 2018 елның “24” августындагы 107 номерлы «Әлмәт муниципаль районы Рус Акташы авыл җирлегенеңдаими нигездә үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затларының, муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәт өчен түләү тәртибе һәм шартлары турында» карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2024 елның 25 сентябрендәге 829 номерлы «Татарстан Республикасында депутатларның,даими нигездә үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затларының, муниципаль берәмлекләрнең контроль-хисап органнары рәисләренең, рәис урынбасарларының, аудиторларның, муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәте өчен түләүгә чыгымнарны формалаштыру нормативлары турында» 2018 елның 28 мартындагы 182 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында» карары нигезендә

Рус Акташы авыл Советы КАРАР БИРӘ:

1. Әлмәт муниципаль районы РусАкташы авыл Советының 2018 елның “24” августындагы 107 номерлы «Әлмәт муниципаль районы Рус Акташы авыл җирлегенең даими нигездә үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затларының, муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәт өчен түләү тәртибе һәм шартлары турында» карарына (Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Рус Акташы авыл Советының Советының 2018 елның 5 декабрендәге 111 номерлы,2020 елның 11 декабрендәге 10 номерлы, 2022 елның 27 октябрендәге 49 номерлы, 2022 елның 14 декабрендәге 54 номерлы карарлары нигезендә кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. карарга 1 нче кушымтадагы таблицаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Әлмәт муниципаль районы Рус Акташы _ авыл җирлегенең муниципаль хезмәткәрләренең вазыйфаи окладлары күләмнәре

| Вазыйфаныңисеме | Вазыйфаи оклад (11 группа хезмәткә түләү) |
| --- | --- |

| | |
|---|---|
| Башкарма комитет җитәкчесе | 20 985 |
| Башкарма комитет җитәкчесенең урынбасары | 20 566» |

1.2. карарга 2 нче кушымтадагы таблицаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Әлмәт муниципаль районы Рус Акташы авыл җирлегенең даими нигездә үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы җирле үзидарәнеңсайлаулы вазыйфаи затларының ай саен акчалата бүләкләү күләмнәре

| Вазыйфаныңисеме | Ай саен акчалата бүләкләү күләме (11 группа хезмәткә түләү) |
|---|---|
| Башлык | 20 991 |
| Башлык урынбасары | 15085» |

2. Әлеге карарны Рус Акташ авылы, Төзүчеләр урамы, 14, Комсомол урамы, 12б, Акташ станциясе территориясендә урнашкан махсус стендларда халыкка игълан итәргә, шулай ук Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм Әлмәт муниципаль районы сайты «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникацион челтәрендә урнаштырырга.

3. Әлеге карар 2025 елның 1 январеннан үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

Рус Акташы авыл җирлеге башлыгы С.А.Белоногов